| | |
|---|---|
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** | **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** |

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**№ 57** **“28” 01 2019 ел**

**Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының муниципаль контроль органнары тарафыннан тәртип бозуларны профилактикалау буенча 2019-2023 елларга мәҗбүри таләпләр программасын раслау турында**

“Дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль уздырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендә кабул ителгән 294-ФЗнче Федераль законның 8.2нче маддәсе һәм 9 маддәсенең 11.3нче бүлеге нигезендә һәм “Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставын кулланып, Татарстан Республикасының Спас муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының муниципаль контроль органнары тарафыннан тәртип бозуларны профилактикалау буенча 2019-2023 елларга мәҗбүри таләпләр Программасын (кушымтаны) расларга.
2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (//htth.pravo.tatarstan.pu) сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Р.Р.Закировага йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе В.А.Осокин

Татарстан Республикасы
Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты карары
белән расланган
28.01. 2019 ел № 57

**2019-2023 елларга**
**Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы**
**муниципаль контроль органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган**
**мәҗбүри таләпләрне**
**бозуларны профилактикалау программасы**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. 2019-2023 елларга Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы муниципаль контроль органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган мәҗбүри таләпләрне бозуларны профилактикалау буенча әлеге Программа «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнгән.

1.2. Программа мәҗбүри таләпләрне үтәмәүнең конкрет сәбәпләрен һәм факторларын ачыклау һәм юкка чыгару, шулай ук профилактика системасын барлыкка китерү һәм үстерүгә юнәлдерелгән профилактик чаралар комплексы булып тора.

1.3. Программа контрольнең түбәндәге төрләре буенча гамәлгә ашырыла:

муниципаль җир контроле;

муниципаль торак контроле.

1.4. Профилактика эшен үткәрүнең максатлары булып торалар:

контроль-күзәтчелек эшчәнлеге системасының үтә күренмәлелеген арттыру;

җир һәм торак законнары өлкәсендә мәҗбүри законнарның бозылышын булдырмый калу;

мәҗбүри таләпләрне бозу нәтиҗәсендә гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян китерү куркынычы янавын булдырмау яки гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян китерү куркынычын булдырмау;

мәҗбүри таләпләрне бозарга һәм гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян китерүгә китерә ала торган һәм зыян китерергә сәләтле сәбәпләрне һәм факторларны бетерү;

контрольдә тотылырга тиешле субъектларның социаль җаваплы һәм намуслы тәртибенә мотивация булдыру;

контроль астындагы субъектларга мәҗбүри таләпләрне аңлату.

1.5. Профилактика эшенең төп максатларына ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итәргә кирәк:

гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян китерүнең яисә зыян китерү ихтималы янавына бәя бирү, аны киметергә ярдәм итүче профилактика чараларын эшләү һәм тормышка ашыру;

мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны ачыклау, хәвеф-хәтәрне бетерү яки киметү ысулларын билгеләү;

контрольдә тотылырга тиешле субъектларның хокукый белемлелеген, шул исәптән мәҗбүри таләпләр һәм аларны үтәү буенча кирәкле чаралар турында мәгълүматның һәркем өчен ачыклыгын тәэмин итү юлы белән арттыру;

контроль- күзәтчелек эшчәнлегендә катнашучыларның барысында да мәҗбүри таләпләрне бер төрле аңлауны формалаштыру;

профилактика чараларын гамәлгә ашыру юлы белән мәҗбүри таләпләр бозылуына профилактика системасын ныгыту;

контроль-күзәтчелек эшчәнлеге кимчелекләрен һәм контроль астындагы субъектларның административ йөкләнешен киметү.

1.6. Программаның максатчан индикаторлары, сыйфаты һәм нәтиҗәлелеге күрсәткечләре булып түбндәгеләр тора:

контрольдә тотылырга тиешле субъектларга мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеге турында мәгълүмат бирү;

мәҗбүри таләпләрнең аңлаешлы булуы, аларга муниципаль контроль органы карамагындагы субъектлар һәм вазыйфаи затлары тарафыннан бер мәгънәдә аңлатма бирү;

контрольдә тотылырга тиешле субъектларның Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Спас муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган кабул ителгән һәм әзерләнүче үзгәрешләр турындагы мәгълүматның ачыклыгын тәэмин ителеше белән канәгать булуы;

контрольдә тотылырга тиешле субъектларның тикшерүләр үткәрү тәртибе, тикшерүләр үткәргәндә хокуклары турында хәбәрдарлыгы;

профилактик программа чараларын үтәү.

Үткәрелгән профилактик чаралар саны программаны гамәлгә ашыруның күләм күрсәткече булып тора.

## 2. Профилактика чараларының план-графигы

| № п/п | Чаралар исемлеге | Чаралар структурасы | Башкару срогы | Җаваплылар: |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Мәгълүматны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру | Үтәлешенә бәя бирү муниципаль контроль астында булган, мәҗбүри таләпләрне үз эченә алган норматив хокукый актлар исемлеген урнаштыру | Даими рәвештә, Кирәге чыккан саен актуальләштерү | Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы (алга таба - ҖММП), Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм ТКХ бүлеге (алга таба – төзелеш һәм ТКХ бүлеге) |
| | | Тикшерүләр планын урнаштыру | ел саен декабрь аенда | ҖММП, төзелеш һәм ТКХ бүлеге |
| | | Контроль чараларның нәтиҗәләлрен урнаштыру | квартал саен | ҖММП, төзелеш һәм ТКХ бүлеге |
| | | Муниципаль контрольне башкарганда контроль-хисап эшчәнлегенең хокукый практикасына күзәтү | квартал саен | ҖММП, төзелеш һәм ТКХ бүлеге |
| | | Контрольдәге субъектларга закон таләпләрен үтәү буенча телефон аша консультацияләр бирү | даими рәвештә | ҖММП, төзелеш һәм ТКХ бүлеге |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 2 | Мәҗбүри таләпләрне үтәү мәсьәләлре буенча мәгълүмат бирү | Киңәшмәләр, очрашулар, семинарлар үткәргәндә мәҗбүри таләпләрне аңлату | ярты елга 1 тапкыр | ҖММП, төзелеш һәм ТКХ бүлеге |
| | | Массакүләм-мәгълүмат чаралары ярдәмендә аңлату эшен үткәрү | елга 1 тапкыр | ҖММП, төзелеш һәм ТКХ бүлеге |
| | | Шәхси кабул итү вакытында закон таләпләрен үтәү мәсьәләләре буенча консультацияләр үткәрү | кабул итү көннәрендә даими рәвештә | ҖММП, төзелеш һәм ТКХ бүлеге |
| 3 | Муниципаль контрольне башкару практикасын гомумиләштерү һәм Интернет челтәрендәге рәсми сайтка урнаштыру | Обобщение и анализ информации по контрольной деятельности | 1 раз в год | ҖММП, төзелеш һәм ТКХ бүлеге |
| | | Мунициапль контроҗ башкару практикасын сайтка урнашытру | ел саен декабрь аенда | ҖММП, төзелеш һәм ТКХ бүлеге |

**3. Ахыргы нәтиҗәләр (гамәлгә ашырылган социаль һәм икътисадый чаралардан нәтиҗә)**

Мәҗбүри таләпләр бозуларга профилактика ясауның көтелгән социаль нәтиҗәсе контрольдә тотыла торган субъектларга артык административ басым ясауны юкка чыгару һәм мәҗбүри таләпләрне үтәү һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча контрольдә тотыла торган субъектлар белән конструктив хезмәттәшлек шартларында гына ирешелергә мөмкин.

Тормышка ашырылган чаралардан икътисади нәтиҗә:

административ басымны киметү, мәҗбүри таләпләрне бозуга юл куймау мәҗбүри таләпләрне бозарга ярамый икәнлеге турында кисәтү планнан тыш тикшерү үткәрүдән нәтиҗәлерәк булган очракларны анык аера белү исәбенә контроль-күзәтчелек эшчәнлегендә катнашучыларның ресурс чыгымнарын киметү;

мәҗбүри таләпләрне бозуның теркәлгән очраклары саны киму;

контрольдә тотылган субъектларның түбән риск категориясенә кертелгән һәм тикшерүләрдән азат ителгән санын арттыру;

муниципаль контроль органнары белән даими хезмәттәшлеккә җәлеп ителгән контрольдә тотылырга тиешле субъектлар санын арттыру

(контрольдәге субъектлар мәҗбүри таләпләрне үтәмәгән очраклар буенча хезмәттәшлектән тыш);

контрольдә тотылырга тиешле субъектларның контроль-күзәтчелек органына карата ышаныч дәрәҗәсен арттыру.